## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

17 ноябрь 2023 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Усай авылында 2024 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Усай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Усай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2024 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Усай торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү (зират территориясен коймалауны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (махсус техникага хезмәт күрсәтү МТЗ - 82.1 тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (Усай торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту);

4) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Усай торак пунктында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов